**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 7 октябрь № 724

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары республика исемлеген һәм Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 28 февраль, 127 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары республика исемлеген һәм Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 28 февраль, 127 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «2014 елга» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

«$2^1$. Әлеге карар белән расланган Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары республика исемлеге һәм Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары республика исемлегенә кертелгән инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин итү тәртибе нигезендә инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары 2016 елның 1 сентябренә кадәр инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин итү буенча исәпкә куелган инвалидларга бирелә дип билгеләргә.»;

әлеге карар белән расланган Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары республика исемлеген яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән);

әлеге карар белән расланган Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары республика исемлегенә кертелгән Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин итү тәртибендә:

түбәндәге эчтәлекле $1.2^1$ пункт өстәргә:

«$1.2^1$. Әлеге Тәртип 2016 елның 1 сентябренә кадәр инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин итү буенча исәпкә куелган инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин итү буенча хокук

мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.»;

1.5 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

1.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин итү инвалидларга федераль дәүләт медицина-социаль экспертиза учреждениеләре эшләгән һәм биргән инвалидларны (инвалид балаларны) тернәкләндерүнең индивидуаль программалары (алга таба – ТИП) яки инвалидларны (инвалид балаларны) тернәкләндерү һәм абилитацияләүнең индивидуаль программалары (алга таба – ТИАП) нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

2.1 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланган ТИП (ТИАП) күчермәсе, әгәр ул Россия Федерациясенең башка субъектында алынган яисә Татарстан Республикасы буенча федераль дәүләт медицина-социаль экспертиза учреждениесе тарафыннан 2011 елның 30 октябренә кадәр (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль яклау министрлыгының «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль яклау министрлыгының 2008 ел, 4 август, 379н номерлы боерыгы белән расланган инвалидны (инвалид балаланы) тернәкләндерүнең индивидуаль программасын эшләү һәм тормышка ашыру тәртибенә үзгәреш кертү турында» 2011 ел, 6 сентябрь, 1020н номерлы боерыгы үз көченә кергән көнгә кадәр) яки 2016 елның 1 гыйнварыннан һәм соңрак (Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «федераль дәүләт медицина-социаль экспертиза учреждениеләре бирә торган инвалидны тернәкләндерү яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын, инвалид баланы тернәкләндерү яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру тәртибен һәм аларның формаларын раслау турында» 2015 ел, 31 июль, 528н номерлы боерыгы үз көченә кергән көннән алып) эшләнгән һәм бирелгән булса. Документлар күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган очракта, инвалид яисә аның вәкиле әлеге документларның төп нөсхәләрен күрсәткәндә, Комплекслы үзәк белгече аларны таныклый;»;

2.2 пунктның өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Комплекслы үзәк инвалид гаризасын карап тикшерә һәм аны теркәгәннән соң эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә инвалидны техник чара белән тәэмин итү буенча исәпкә кую турында (исәпкә куюдан баш тарту турында) карар кабул итә һәм инвалидка исәпкә кую турында (исәпкә куюдан баш тарту турында) язмача хәбәр җибәрә.

Инвалидка техник чара белән тәэмин итү буенча исәпкә куюдан баш тарту өчен нигезләр түбәндәгеләр:

инвалид яки аның вәкиле әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмавы;

гаризада, ТИП (ТИАП) рекомендацияләрендә күрсәтелгән техник чара төре булмау;

гаризада һәм ТИП (ТИАП) рекомендацияләрендә күрсәтелгән техник чара төре Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары республика исемлегендә

булмау;

әлеге Тәртипнең 2.1 пунктындагы дүртенче абзацта күрсәтелгән документны аның гамәлдә булу вакыты үткәннән соң күрсәтү һәм (яки) тапшыру.»;

2.4 пунктның икенче абзацындагы «, шулай ук бу хакта язмача хәбәрне инвалидка җибәрү» сүзләрен өстәргә;

2.5 пунктта:

беренче абзацка «гамәлгә ашырыла» сүзләренә кадәр «Комплекслы үзәк тарафыннан тиешле мәгълүмат алынган көннән соң бер эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацта «инвалидка ТИП» сүзләрен «инвалидка ТИП (ТИАП)» сүзләренә алмаштырырга;

4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Инвалид техник чараны ике нөсхәдә төзелә торган алу-бирү акты буенча шартнамәдә билгеләнгән вакытта, шул исәптән шартнамәне вакытыннан алда өзгән очракта, төзек хәлдә кире кайтарырга тиеш, техник чараның алга таба файдаланып булмау хәленә килүендә инвалидның гаебе булмаган очраклардан тыш, моны Комплекслы үзәк боерыгы белән төзелгән комиссия бәяләмәсе раслый.

Комплекслы үзәк шартнамә шартлары үзгәрү, шартнамәнең гамәлдә булу вакыты чыгу белән бәйле, әлеге Тәртипнең 4.8 пунктында күрсәтелгән очрактан тыш, шулай ук шартнамәне вакытыннан алда өзү очрагында инвалид техник чараны кире кайтарган көндә техник чараны алу-бирү акты буенча кабул итеп алырга тиеш.»;

4.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5. Шартнамә Россия Федерациясе Граждан кодексында, бүтән федераль законнарда яки шартнамәдә каралган нигезләр буенча вакытыннан алда өзелә, шул исәптән:

инвалид башлангычы белән;

Комплекслы үзәк боерыгы белән төзелгән комиссия бәяләмәсе раслаган алга таба файдаланып булмау хәленә килгән техник чараны төзәтү яки алыштыру зарурлыгы барлыкка килгән очракта.

Инвалид үлгән очракта шартнамәнең гамәлдә булуы туктатыла.

Шартнамәдә аны вакытыннан алда өзү, үзгәртү, туктатып тору, шулай ук гамәлдә булу вакытны озайту тәртибе һәм шартлары билгеләнә. Шартнамә формасын Министрлык раслый.»;

4.6 һәм 4.7 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\724.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 28 февраль, 127 нче карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 7 октябрь, 724 нче карары редакциясендә)

## ИНВАЛИДЛАРНЫ ТЕРНӘКЛӘНДЕРҮНЕҢ ТЕХНИК ЧАРАЛАРЫ РЕСПУБЛИКА ИСЕМЛЕГЕ

| Т/с | Тернәкләндерүнең техник чарасы төре | Хезмәт күрсәтү вакыты, ел |
|---|---|---|
| 1. | БЦП булган балалар өчен махсус кресло | кимендә 5 |
| 2. | Ванна өчен күтәрү җайланмасы | кимендә 5 |
| 3. | Функциональ кровать | кимендә 7 |
| 4. | Тернәкләндерү костюмы | кимендә 3 |
| 5. | Электр күтәргеч | кимендә 7 |
| 6. | Гидравлик күтәргеч | кимендә 7 |
| 7. | Вертикализатор | кимендә 7 |
| 8. | Күпфункциональ велотренажер | кимендә 5 |
| 9. | DM-450 тавышландырылган навигация белән санлы диктофон | кимендә 5 |
| 10. | GPS радиоалгычлы, текстлы тоташтыргыч белән, экранга сөйләм белән тәэсир итеп була тораган, күрү буенча инвалидлар өчен телефон (GSM) | кимендә 7 |
| 11. | Үткәрелә торган тернәкләндерү чараларын өй шартларында ерактан торып мониторинглау өчен видеокамера белән нетбук | кимендә 3 |
| 12. | Экранга сөйләм белән тәэсир итеп була торган программалы ноутбук (нетбук) | кимендә 3 |

___